ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
423750, Уразай авылы,
Центральная урамы, 4 нче йорт.
тел.3-44-62
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

УРАЗАЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423750, дер.Уразаево,
ул.Центральная,
дом 4., тел. 3-44-62.
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
20.05.2020 ел

КАРАР
№11

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразаай авыл җирлегенең 2020 елгы су коену сезоны чорында ачык сулыкларда коенуны тыю турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Уразай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 маендагы ПР-95 номерлы карары белән, Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясендә пляжлар һәм суда күпләп ял итү өчен оештырылган башка урыннар булмау сәбәпле, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында, сулыкларда гражданнарның иминлеген тәэмин итү мөмкинлеге бирә торган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясендә урнашкан ачык сулыкларда гражданнарны 2020 елгы су коену сезоны чорында коенуны тыярга.
2. Су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда су коенуны тыю һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклеге турында белешмәлекләр тапшырып халык белән аңлату эшләре алып барырга.
3. Балаларның өлкәннәр тарафыннан караучысыз һәм күзәтүсез булган гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән индивидуаль профилактик эш алып барырга, ата-аналарга имза астында коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга.
4. Су коенуны тыю турында ачык сулыклар янында аншлаглар куярга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Уразай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Уразай авыл җирлеге башкарма
Комитет җитәкчесе Шарипов Р.Р.